| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУЛАНГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОЛАНГЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |

12 октябрь, 2019 ел Колаӊгы станциясе № 2

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге Колаңгы станцисе торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2019 елның 22 октябренә 14 сәг 00 минутка Колаңгы станциясе пос., Шоссейная ур, 30 йорт адресы буенча урнашкан МФЦ “ИРИДА” бинасында, үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“ Сез 2020 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлегенең Колаңгы торак пункты территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?”

*а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру*:

- торак пунктлардагы урам утларын ремонтлау;

*б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- материаллар сатып алып, су челтәрләрен ремонтлау;

*в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка таратырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колангы авыл жирлеге башлыгы** **Ф.Т.Нигматзянов**